ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЧУВАШСКО-ЕЛТАНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422962, Республика Татарстан,
Чистопольский район,
с. Чувашский Елтан, ул. Школьная, д.15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЧУАШ ЯЛТАНЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422962, Татарстан Республикасы,
Чистай районы, Чуаш Ялтаны авылы,
Мәктәп ур., 15 йорт

тел. 8(84342) 3-69-33 e-mail: Celt.Ctp@tatar.ru

***Постановление*** ***Карар***

**2022 елның 31 гыйнвары** **№ 3**

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Чуаш Ялтаны авыл җирлегендә җирләү буенча
хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә
күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

«Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 3 пункты һәм 12 статьясындагы 3 пункты (үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертеп), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары нигезендә, Чистай муниципаль районы Чуаш Ялтаны авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чуаш Ялтаны авыл җирлегендә әлеге карарның 1 нче кушымтасы һәм 2 нче кушымтасы нигезендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә 6964,68 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 2022 елның 1 февраленнән билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чуаш Ялтаны авыл җирлегенең «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чуаш Ялтаны авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында» 2019 елның 30 гыйнварындагы 2а номерлы карарын 2022 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Чуаш Ялтаны авыл җирлеге
башлыгы С.М. Егоров

Чистай муниципаль районының
Чуаш Ялтаны авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2022 елның 31 гыйнварындагы
3 номерлы карарына
1 нче кушымта

2022 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чуаш Ялтаны авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе, сум |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2. Җирләү өчен табут һәм башка кирәк-яраклар бирү һәм китерү | 4933,99 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка илтү | 699,75 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1330,94 |
| БАРЛЫГЫ | 6964,68 |

Чистай муниципаль районының
Чуаш Ялтаны авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2022 елның 31 гыйнварындагы
3 номерлы карарына
2 нче кушымта

2022 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чуаш Ялтаны авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе, сум |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2. Кәфенләү | 2465,5 |
| 3. Җирләү өчен табут һәм башка кирәк-яраклар бирү һәм китерү | 2465,5 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка илтү | 696,5 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1337,18 |
| БАРЛЫГЫ | 6964,68 |